| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>СОВЕТЫ |

| | | |
|---|---|---|
| **РЕШЕНИЕ**<br>**12.07.2017** | Зеленодольск шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 202** |

Зеленодольск муниципаль районы Советының 2005 елның 14 декабрендәге 18 номерлы карары белән кабул ителгән «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Зеленодольск муниципаль районы Советы карары проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү һәм карар проекты хакында

Зеленодольск муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясе рәисе Г.Т. Савельевның Зеленодольск муниципаль районы Советының 2005 елның 14 декабрендәге 18 номерлы карары белән кабул ителгән «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Зеленодольск муниципаль районы Советы карары проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү һәм карар проекты хакында мәгълүматын тыңлап һәм фикер алышканнан соң , «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, 2006 елның 6 мартындагы «Террорчылыкка каршы гамәлләр турында» 35-ФЗ номерлы Федераль закон, 2017 елның 3 апрелендәге «Коррупциягә каршы тору өлкәсендә дәүләт сәясәтен камилләштерү максатларында, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 64-ФЗ номерлы Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 15, 99-101 статьялары, Зеленодольск муниципаль районында гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә нигезендә,Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды**:

1. Зеленодольск муниципаль районы Советының 2005 елның 14 декабрендәге 18 номерлы карары белән кабул ителгән «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Зеленодольск муниципаль районы Советы карары проектын хупларга һәм гавами тыңлауларга(1 нче кушымта).

2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән Зеленодольск муниципаль районы Советының карар проекты буенча гавами тыңлаулар уздыруны билгеләргә.

3. Гавами тыңлаулар уздыруның инициаторы булып Зеленодольск муниципаль районы Советы тора.

4. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

4.1. гавами тыңлаулар уздыру датасы һәм вакыты - 2017 елның 21 августы, 16.00 сәгатьтә.

4.2. гавами тыңлаулар уздыру вакыты - 1 көн;

4.3. гавами тыңлаулар уздыру урыны - Зеленодольск шәһәре, Ленин ур., 46нчы йорт, А.М.Горький исемендәге мәдәният, сәнгать һәм халык иҗаты үзәге;

5. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына:

5.1. Зеленодольск муниципаль районының гамәлдәге законнар, норматив хокукый актлары нигезендә һәм шушы карарда билгеләнгән срокларда әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән Зеленодольск муниципаль районы Советының карары проекты буенча гавами тыңлауларны әзерләргә һәм уздырырга;

5.2. гавами тыңлаулар тәмамланганнан соң, тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләргә һәм 2017 елның 29 августына кадәр халыкка мәгълүмат бирүне тәэмин итәргә.

6. Әлеге карарга 2 нче кушымтада каралганча, Зеленодольск муниципаль районы Советының 2005 елның 14 декабрендәге 18 номерлы карары белән кабул ителгән «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Зеленодольск муниципаль районы Советы карары проектына гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алырга һәм аның буенча фикер алышуда катнашу тәртибен расларга.

7. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән Зеленодольск муниципаль районы Советы карары проектына гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм аның буенча фикер алышуда гражданнарның катнашуы әлеге карарның 6 пунктында күрсәтелгән тәртип нигезендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

8. 2017 елның 20 июленә кадәр әлеге карарны һәм әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән карар проектын Интернет челтәрендә Татарстан Республикасының (http://pravo.tatarstan.ru) хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының (http://zelenodolsk.tatarstan.ru)мәгълүмат сайтында урнаштырырга.

9. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Зеленодольск**
**муниципаль районы**
**Башлыгы,**
**Советы рәисе** **А. В. Тыгин**

Зеленодольск муниципаль районы Советының 2017 елның 12 июлендәге 202 номерлы карарына

1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советы карары проекты**

2017 елның «____»_______________ №

Зеленодольск муниципаль районы Советының 2005 елның 14 декабрендәге 18 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Террорчылыкка каршы тору турында» 2006 елның 6 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына коррупциягә каршы көрәш өлкәсендә дәүләт сәясәтен камилләштерү максатларында үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 3 апрелендәге 64-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең 15, 99-101 статьялары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды**:

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының 2005 елның 14 декабрендәге 18 номерлы карары белән кабул ителгән «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына (Зеленодольск муниципаль районы Советының 2006 елның 31 октябрендәге 96 номерлы, 2007 елның 9 июлендәге 190 номерлы, 2008 елның 10 июнендәге 313 номерлы, 2008 елның 20 октябрендәге 378 номерлы, 2010 елның 16 июнендәге 524 номерлы, 2012 елның 15 мартындагы 134 номерлы, 2012 елның 29 декабрендәге 223 номерлы, 2014 елның 21 февралендәге 361 номерлы, 2015 елның 5 мартындагы 492 номерлы, 2015 елның 28 августындагы 561 номерлы, 2016 елның 15 февралендәге 61 номерлы, 2016 елның 27 июнендәге 99 номерлы, 2017 елның 14 февралендәге 169 номерлы карарларына кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 7 статьяда:

1.1) 7 статьяның 1 өлешендәге 10 пунктында «каникуллар вакытында балаларның ялын оештыру;» сүзләрен «каникуллар вакытында балаларның ялын оештыруны тәэмин итү буенча чараларны үз вәкаләтләре чикләрендә гамәлгә ашыру, аларның тормышы һәм сәламәтлеге иминлеген тәэмин итү чараларын да кертеп;» сүзләренә алмаштырырга;

1.2) түбәндәге эчтәлекле 4 өлеш өстәргә:

«4. Федераль законнарда билгеләнгән очракларда Татарстан Республикасы законнары белән җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында вәкаләтләрне яңадан бүлү гамәлгә ашырылырга мөмкин.»;

2) 15 статьяда:

2.1) 15 статьяның 3 өлешендәге 1 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«1) район Уставы проекты, шулай ук әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль норматив хокукый акт проекты, әлеге Уставны әлеге норматив хокукый актларга туры китерү максатларында, район Уставына Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе яки Татарстан Республикасы законнары нигезләмәләрен төгәл кабатлау формасында үзгәрешләр кертелгән очраклардан тыш;»;

3) 26 статьяда:

3.1) 26 статьяның 6 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Район Советы депутаты «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, бурычларны үтәргә тиеш. Депутатның, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затының, муниципаль вазыйфаны биләүче башка затның вәкаләтләре «Коррупциягә каршы тору турында»2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон белән, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм аларның керемнәренә башка затлар чыгымнарының туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон белән, «Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм счетлар (кертемнәр) булдыруны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләр, тыюлар, бурычларны үтәмәү очрагында, вакытыннан алда туктатыла.

3.2.) түбәндәге эчтәлекле 26 статьяны 7, 8, 9 нчы өлешләр белән тулыландырырга:

«7. Район Советы депутатының коррупциягә каршы тору турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә тапшырыла торган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасының югары вазыйфаи заты (Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесе) карары буенча уздырыла.

8. Әлеге статьяның 7 өлеше нигезендә үткәрелгән тикшерү нәтиҗәсендә «Коррупциягә каршы тору турында»2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон белән, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм аларның керемнәренә башка затлар чыгымнарының туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон белән, «Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм счетлар (кертемнәр) булдыруны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю

турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны , бурычларны үтәмәү фактлары ачыкланганда, Татарстан Республикасы югары вазыйфаи заты (Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте югары башкарма органы җитәкчесе) район Советы депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында гариза белән тиешле карар кабул итәргә вәкаләтле булган район Советына яки судка мөрәҗәгать итә.

9. Муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр Зеленодольск муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге мәгълүмат сайтында урнаштырыла һәм (яисә) массакүләм мәгълүмат чараларына муниципаль хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгару өчен тапшырыла.»

4) 29 статьяда:

4.1) 29 статьяның 1 өлешендәге 9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9) Районның Башкарма комитеты җитәкчесе, контроль-хисап палатасы рәисе һәм аудиторларын, Финанс-бюджет палатасы җитәкчесен, Мөлкәти һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы җитәкчесен билгеләп кую, аларның отставкасын кабул итү;»;

5) 35 статьяда:

5.1) 35 статьяның 1.1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасының югары вазыйфаи заты (Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесе) депутат вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында гариза белән мөрәҗәгать иткән очракта, вәкаләтләрне вакытыннан алда туктату өчен нигез барлыкка килгән көн, әлеге гаризаның Район Советына кергән көне була.»;

6) 38 статьяда:

6.1) 38 статьяның 2.1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Район Башлыгы «Коррупциягә каршы тору турында»2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон белән, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм аларның керемнәренә башка затлар чыгымнарының туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон белән, «Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм счетлар (кертемнәр) булдыруны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны , бурычларны үтәргә тиеш.»;

7) 40 статьяда:

7.1) 40 статьяның 1.1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Район Башлыгының вәкаләтләре «Коррупциягә каршы тору турында»2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон белән, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм аларның керемнәренә башка затлар чыгымнарының туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон белән, «Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм счетлар (кертемнәр) булдыруны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 7

маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны , бурычларны үтәмәүгә бәйле рәвештә вакытыннан алда туктатыла.

7.2) 40 статьяга түбәндәге эчтәлекле 1.2, 1.3 өлешләр өстәргә:

«1.2. Район Башлыгын отставкага җибәрү турындагы мәсьәләне караганда, утырыш Район Советы депутаты, Район Советы тарафыннан моңа вәкаләтле булган, рәислегендә уза.

1.3. Район Башлыгы вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган яки суд карары буенча аңа карата сак астына алу яки вакытлыча вазифасыннан читләштерү рәвешендә процессуаль мәҗбүри чаралар кулланылган очракта, аның вәкаләтләрен вакытлыча Район Башлыгы урынбасары башкара.»;

8) IV бүлекне түбәндәге эчтәлекле 40.1 статья белән тулыландырырга:

**8.1) «40.1 статья. Муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга салына торган чикләүләр һәм вазыйфалар**

1. Район Башлыгы, Район башлыгы урынбасары вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар һәм Район Башлыгы вазыйфаларын биләүче затлар, үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре, шулай ук үз хатыннарының (ирләренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында Татарстан Республикасының югары вазыйфаи затына(Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте югары башкарма органы җитәкчесенә) Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән тәртиптә мәгълүмат тапшыралар.

2. Район Башлыгы, Район Башлыгы урынбасары вазыйфаларын биләүче затлар тапшырган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турындагы белешмәләр «Интернет» мәгълүмати - телекоммуникация челтәрендә Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында урнаштырыла һәм (яисә) массакүләм мәгълүмат чараларына муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгару өчен бирелә.

3. Әлеге статьяның 1 өлеше нигезендә тапшырыла торган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасының иң югары вазыйфаи заты (Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесе) карары буенча гамәлгә ашырыла.

4. Әлеге статьяның 3 өлеше нигезендә үткәрелгән тикшерү нәтиҗәсендә Район Башлыгы, Район Башлыгы урынбасары вазыйфасын биләүче затның «Коррупциягә каршы тору турында»2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон белән, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм аларның керемнәренә башка затлар чыгымнарының туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон белән, «Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм счетлар (кертемнәр) булдыруны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләр, тыюлар, вазыйфаларын үтәмәве фактлары ачыкланганда, Татарстан Республикасы югары вазыйфаи заты (Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте югары башкарма органы җитәкчесе) Район башлыгы, Район Башлыгы урынбасары вазыйфасын биләүче затның

вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату яисә аның башка дисциплинар җәзасына карата тиешле карар кабул итәргә вәкаләтле Район Советына яисә судка мөрәҗәгать итә.»;

9) 44 статьяда:

9.1) 44 статьяның исемендә, «Башкарма комитет» сүзләреннән соң «Район» сүзен өстәргә;

9.2) 44 статьяның 1 өлеше исемендә, «Башкарма комитет» сүзләреннән соң «Район» сүзен өстәргә;

9.3) 44 статьяның 1 өлешендәге 7 пунктының дүртенче абзацын төшереп калдырырга;

9.4) 44 статьяның 1 өлешендәге 10 пунктын 11 пункт дип санарга, 10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10) террорчылыкны профилактикалауда катнашу буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл иткәндә, шулай ук аның нәтиҗәләрен минимальләштергәндә һәм (яисә) юкка чыгарганда:

- террорчылыкны профилактикалау, шулай ук аның нәтиҗәләрен минимальләштерү һәм (яисә) юкка чыгару өлкәсендә муниципаль программалар эшли һәм гамәлгә ашыра;

- Районда терроризмның асылын һәм аның иҗтимагый куркынычын аңлату буенча , шулай ук гражданнарда террорчылык идеологиясен кабул итмәү, шул исәптән мәгълүмати материаллар, басма продукция тарату, аңлату эшләре һәм башка чаралар үткәрү юлы белән мәгълүмати-пропаганда чаралары оештыра һәм үткәрә;

- федераль башкарма хакимият органнары һәм (яки) Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары оештырган терроризмны профилактикалау, шулай ук аның нәтиҗәләрен киметү һәм (яки) бетерү буенча чараларда катнаша;

- муниципаль милектәге яисә җирле үзидарә органнары карамагындагы объектларның террорчылыктан сакланышына карата таләпләрнең үтәлешен тәэмин итә;

- терроризмны профилактикалауда, шулай ук аның нәтиҗәләрен киметүдә һәм (яки) бетерүдә катнашу мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарына тәкъдимнәр җибәрә;

- терроризмны профилактикалауда, шулай ук аның нәтиҗәләрен киметүдә һәм (яки) бетерүдә катнашу буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча башка вәкаләтләр башкара;»;

9.5) 44 статьяның 2 өлешендәге 4 пунктындагы икенче абзацны төшереп калдырырга;

9.6) 44 статьяның 2 өлешендәге 5 пунктын 6 пункт дип санарга, 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) террорчылыкны профилактикалауда катнашу буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл иткәндә, шулай ук аның нәтиҗәләрен минимальләштергәндә һәм (яисә) юкка чыгарганда:

- террорчылыкны профилактикалау, шулай ук аның нәтиҗәләрен минимальләштерү һәм (яисә) юкка чыгару өлкәсендә муниципаль программалар эшли һәм гамәлгә ашыра;

- муниципаль берәмлекләрдә террорчылыкның асылын һәм аның иҗтимагый куркынычын аңлату, шулай ук гражданнарда террорчылык идеологиясен кабул итмәү, шул исәптән мәгълүмати материаллар, басма продукция тарату, аңлату эше һәм башка чаралар үткәрү юлы белән, мәгълүмати-пропаганда чаралары оештыра һәм үткәрә;

- федераль башкарма хакимият органнары һәм (яки) Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары оештырган терроризмны профилактикалау, шулай ук аның нәтиҗәләрен киметү һәм (яки) бетерү буенча чараларда катнаша;

- муниципаль милектәге яисә җирле үзидарә органнары карамагындагы объектларның террорчылыктан сакланышына карата таләпләрнең үтәлешен тәэмин итә;

- терроризмны профилактикалауда, шулай ук аның нәтиҗәләрен киметүдә һәм (яки) бетерүдә катнашу мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарына тәкъдимнәр җибәрә;

- терроризмны профилактикалауда, шулай ук аның нәтиҗәләрен киметүдә һәм (яки) бетерүдә катнашу буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча башка вәкаләтләр башкара;»;

10) 44.2 статьяда:

10.1) 44.2 статьясындагы 7 пунктының бишенче абзацын төшереп калдырырга;

10.2) 44.2 статьяның 10 пунктын 11 пункт дип санарга, 10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10) террорчылыкны профилактикалауда катнашу буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл иткәндә, шулай ук аның нәтиҗәләрен минимальләштергәндә һәм (яисә) юкка чыгарганда:

- террорчылыкны профилактикалау, шулай ук аның нәтиҗәләрен минимальләштерү һәм (яисә) юкка чыгару өлкәсендә муниципаль программалар эшли һәм гамәлгә ашыра;

- шәһәр җирлегендә террорчылыкның асылын һәм аның иҗтимагый иминлеген аңлату буенча мәгълүмати-пропаганда чаралары оештыра һәм үткәрә, шулай ук гражданнарда террорчылык идеологиясен кабул итмәү, шул исәптән мәгълүмати материаллар, басма продукция тарату, аңлату эшләре һәм башка чаралар үткәрү юлы белән.

- федераль башкарма хакимият органнары һәм (яки) Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары оештырган терроризмны профилактикалау, шулай ук аның нәтиҗәләрен киметү һәм (яки) бетерү буенча чараларда катнаша;

- муниципаль милектәге яисә җирле үзидарә органнары карамагындагы объектларның террорчылыктан сакланышына карата таләпләрнең үтәлешен тәэмин итә;

- терроризмны профилактикалауда, шулай ук аның нәтиҗәләрен киметүдә һәм (яки) бетерүдә катнашу мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарына тәкъдимнәр җибәрә;

- терроризмны профилактикалауда, шулай ук аның нәтиҗәләрен киметүдә һәм (яки) бетерүдә катнашу буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча башка вәкаләтләр башкара;»;

11) 45 статьяда:

11.1) 45 статьяның 3.1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Башкарма комитет җитәкчесе «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм аларның керемнәренә башка затлар чыгымнарының туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон, «Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм счетлары (кертемнәре) булуны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, бурычларны үтәргә тиеш.»;

12) 49 статьяда.:

12.1) 49 статьяның 2 өлешендә 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) Россия Федерациясенең коррупциягә каршы тору турындагы законнары нигезендә бирелә торган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләр турындагы мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү нәтиҗәсендә ачыкланган,Татарстан Республикасы Президентының - Федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән Районның җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга кагылышлы өлештәге контракт шартларын бозуга бәйле рәвештә, шулай ук әлеге Уставның 45 статьясындагы 3 пунктында билгеләнгән чикләүләрне үтәмәүгә бәйле рәвештә, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм аларның керемнәренә башка затлар чыгымнарының туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон, «Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм счетлары (кертемнәре) булуны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, йөкләмәләрне үтәмәүгә бәйле рәвештә;»;

12.2) 49 статьяга түбәндәге эчтәлекле 3 өлеш өстәргә:

«3. Район Башкарма комитеты җитәкчесе вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган йә аңа карата суд карары белән сак астына алу яисә вазыйфасыннан вакытлыча читләштерү рәвешендә процессуаль мәҗбүр итү чаралары кулланылган очракта, аның вәкаләтләре вакытлыча Район Башкарма комитеты җитәкчесенең урынбасарларының берсе тарафыннан Районның Башкарма комитетында билгеләнгән бурычларны бүлү нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

13) 66 статьяда:

13.1) 66 статьяда түбәндәге эчтәлекле 2.1 пункт өстәргә:

«2.1. Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга һәм алар нигезендә кабул ителә торган Татарстан Республикасы законнарына әлеге

Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында Район Уставының, муниципаль хокукый актның каршылыгы рөхсәт ителми.»;

14) 80 статьяда:

14.1) 80 статьяның 1өлешендәге 3 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«3) шәхсән яисә ышанычлы затлар аша эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнергә, коммерция оешмасы идарәсендә яисә коммерциягә карамаган оешма идарәсендә (сәяси партия идарәсендә катнашудан тыш); иҗтимагый оешманың, торак, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативларының, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтләренең съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында катнашу; федераль законнарда каралган очраклардан тыш, оешмада каралган очракларда һәм җирле үзидарә органы исеменнән идарә итүдә катнашу очракларыннан тыш, әлеге коммерциягә карамаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) тарафыннан бер кеше башкара торган башкарма орган буларак идарә итүдә яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүендә (эш бирүче) катнашу, федераль законнарда каралган тәртиптә яллаучы вәкиленең (эш бирүче) рөхсәте белән бергә, һәм җирле үзидарә органы исеменнән идарә итүдә катнашу;»;

15)80.2 статьяда:

15.1)80.2 статьяга түбәндәге эчтәлекле 5,6,7,8 өлешләр өстәргә:

«5. Контракт буенча Башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасына дәгъва кылучы гражданнар һәм күрсәтелгән вазыйфаны биләүче зат үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмә, шулай ук үз хатыннарының (ирләренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәне Татарстан Республикасының югары вазыйфаи затына (Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесенә)Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән тәртиптә тапшыралар.

6. Контракт буенча Башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләүче тарафыннан тәкъдим ителгән затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр Зеленодольск муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге мәгълүмат сайтында урнаштырыла һәм (яисә) муниципаль хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен бирелә.

7. Әлеге статьяның 6 өлеше нигезендә тапшырыла торган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасының иң югары вазыйфаи заты (Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесе) карары буенча гамәлгә ашырыла.

8. Әлеге статьяның 7 өлеше нигезендә башкарылган тикшерү нәтиҗәсендә контракт буенча Башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләүче затның «Коррупциягә каршы тору турында»2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон белән, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм аларның керемнәренә башка затлар чыгымнарының туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон белән, «Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә

урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм счетлар (кертемнәр) булдыруны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләр, тыюлар, вазыйфаларын үтәмәве фактлары ачыкланганда, Татарстан Республикасының югары вазыйфаи заты (Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте югары башкарма органы җитәкчесе) контракт буенча җирле хакимият башлыгы вазыйфасын биләүче затның вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату яки аңа карата башка дисциплинар җәзаны куллану турында гариза белән тиешле карар кабул итәргә вәкаләтле Район Советына яки судка мөрәҗәгать итә.»;

16) 99 статьяда:

16.1)99 статьяның 3 өлешендәге икенче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Район Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында Район Советы карары проекты буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибен, шулай ук район Уставына Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе нигезләмәләрен төгәл кабатлау рәвешендә үзгәрешләр кертелгәндә, гражданнарның әлеге норматив хокукый актларга туры китерү максатларында фикер алышуда катнашу тәртибен рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) таләп ителми.».

2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве өчен җибәрергә.

3. Әлеге карарны дәүләт теркәвенә алганнан соң Интернет челтәрендә Татарстан Республикасының (http://pravo.tatarstan.ru) хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) мәгълүмат сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясындагы 8 өлеше, Татарстан Республикасының «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлек Уставының 101 статьясындагы 2,3 өлешләре нигезендә үз көченә керә дип билгеләргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Зеленодольск муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Зеленодольск муниципаль районы**

**Башлыгы, Совет рәисе** **А. В. Тыгин**

Зеленодольск муниципаль районы Советының 2017 елның 12 июлендәге 202 номерлы карарына

2 нче кушымта

«Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советы карары белән кабул ителгән 2005 елның 14 декабрендәге 18 номерлы карар проектына гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибе һәм гражданнарның аны тикшерүдә катнашуы

1. «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советы карары белән кабул ителгән 2005 елның 14 декабрендәге 18 номерлы карар проектына тәкъдимнәр Зеленодольск муниципаль районы Советына Зеленодольск муниципаль районы Советына түбәндәге адрес буенча: Зеленодольск шәһәре, Ленин урамы, 41а йорты, 306 нчы каб., кушымтада бирелгәнчә үрнәк буенча, төзәтмәләр таблицасы рәвешендә язма формада кертелә:

| № т/б | Пункт, пунктча | Карар проекты тексты | Төзәтмә тексты | Төзәтмәне исәпкә алып, проект тексты | Төзәтмәләр авторы (Ф.И.Ат.и., адресы, эш , уку урыны) |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

Тәкъдимнәр Интернет челтәрендә Татарстан Республикасының (http://pravo.tatarstan.ru) хокукый мәгълүмат рәсми порталында карар урнаштырылган көннән алып, бер ай эчендә, 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр кабул ителә.

2. Гавами тыңлауларда катнашу өчен заявкалар Зеленодольск шәһәре, Ленин урамы, 41а йорты, 306 нчы каб. адресы буенча шәхсән тапшырыла

Заявкалар эш көннәрендә 8.00-17.00 сәгатьләрдә гавами тыңлаулар уздыру көненә кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча кабул ителә.

3. Гражданнарның тәкъдимнәре Зеленодольск муниципаль районы Советы аппараты хезмәткәрләре тарафыннан теркәлә һәм Зеленодольск муниципаль районы Советының 2006 елның 15 декабрендәге 131 номерлы карары белән расланган Зеленодольск муниципаль районында гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә ярашлы рәвештә, карау өчен Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына тапшырыла.